| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.03.2024 ел Баулы шәһәре №45

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 230 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына (2023 елның 17 апрелендәге 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы (2024 елның 16 гыйнварыннан ред.) «Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең территориаль подсистемасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 230 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә (2023 елның 17 апрелендәге 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Комиссия составына кертергә:

- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигын;
- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесен;
- «Безнең ишегалды» торак милекчеләре ширкәте рәисен (килешү буенча).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам .

Җитәкче Д.Л. Бакиров